КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 март г.Казань № 258

2022 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында

2022 елда федераль бюджеттан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен тормышка ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән аерым чараларны тормышка ашыру турында» 2022 елның 18 мартындагы 409 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашырганда Россия Федерациясе субъектларының барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:
2022 елда Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашырганда Татарстан Республикасының барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен;
2022 елда эш бирүчеләрнең яраклы эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнар (эшсез гражданнарны кертеп) өчен җәмәгать эшләрен оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын

һәм оешмаларның эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү һәм матди-техник җиһазландыру чыгымнарын каплау тәртибен.

2. Бу карарны куллану буенча аңлатмалар бирү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин